# КОМСОМОЛГА 100 ЕЛ.

Шушы уңайдан башта төрле уйлар, хатирәләр, истәлекләр туды. Шулар турында язып үтмәкче булам. Минем уйлануларым белән килешергә яки, киресенчә, килешмәскә була. Уйланулар бит алар һәрбер кешенең үзенең карашын күрсәтә.

Безнең буын октябрят та, пионер да, комсомол да булды. Һәрберсенең рәтендә булу безнең өчен зур шатлык та, җаваплылык та иде. Комсомолга керү өчен башта октябрят һәм пионер булырга кирәк иде.

Башлангыч класста бөдрә чәчле кечкенә Ленинның сурәте төшкән значокны күкрәккә таккач, безнең сөенүнең очы-кырые булмады. Урта сыйныфка күчкәч, бик нык әзерләнеп, антлар биреп, пионерга кердек. Муенга кызыл галстук тагу, кулны маңгайга күтәреп, салют бирү – боларның барысына да өйрәнергә кирәк булды. Ул галстук белән төрле хәлләр була иде. Кызлар тәртиплерәк булгангадыр инде, галстук тагып, мәктәпкә килү алар өчен авыр булмагандыр дип уйлыйм. Ә малайларның кайберләре өчен бу күп кенә җайсызлыклар китереп чыгара иде. Кесәдә йөреп, ефәк галстук чүпрәккә әйләнеп, бөгәрләнеп бетә. Дәрес алдыннан тиз генә муенга тагып куялар, ул, бөдрәләнеп, иясенең тәртибен фаш итә. Пионервожатый Әдия апаның күзенә күренергә ярамый, юкса әйбәт кенә эләгәчәк. Ә барабан кагу, быргы кычкырту теләге бөтенебезгә дә хас иде. Пионер бүлмәсе без тау башында укыганда аерым бинада иде. Анда ике класс укый, ә тагын бер бүлмә китапханәгә һәм пионер оешмасына бирелгән иде. Ул бүлмә бервакытта да буш тормады. Тынгысыз Әдия апа һәрвакыт нәрсә булса да әзерли, класстан тыш эшләр алып бара. Шул бина янында кыш көне байраклар, барабаннар, быргылар тотып төшкән фото әле дә булса шул заманнарны хәтерләтә.

Югары класска күчкәч, тагын бер адым – комсомолга керүгә хәзерләнү булды. Бу адым тагын да җитдирәк иде. Комсомоллар бөтен дөньяны шаулатып яңа төзелешләрдә, моңарчы кеше аягы басмаган җирләрне күтәрүдә, тимер юллар салуда, космосны буйсындыруда һәм бүтән алдынгы эшләрдә катнашалар. Радио алар турындагы чыгышлар белән тулы. Мәктәптә инде Әдия апа түгел, ә зур класс укучылары җитәкчелек итә. Алар безгә бераз түбәнсетеп караган кебек. Тизрәк шул комсомолга керәсе килә. Анда кергәндә ныклап тикшерәләр: тәртибең ничек, нинди билгеләргә укыйсың, мәктәптән тыш эшләрдә катнашасыңмы, Ленин васыятләрен үтисеңме...

Һәр дүшәнбе мәктәптә озын тәнәфестә линейка үтә. Анда яңалыклар белән таныштыралар. Күбрәк тәртип бозучыларны тикшерәләр. Без укыганда, завуч булгангадыр инде, линейканы Хәй абый алып барганы хәтеремдә. Малайлар, мәктәп артына чыгып, кача-поса тәмәке тартканнар. Хәй абый шуны күргән. Шул турыда ул болай дип аңлатты: “Менә күрәсезме мин нинди кыска буйлы калдым, тәмәке тартканга күрә. Кызлар озын буйлы егетләрне яраталар. Аннан соң сездән тәмсез исләр дә килеп тора бит әле. Әгәр матур, озын булып үсәсегез, сәләмәт каласыгыз, кызларга ошыйсыгыз килсә тартмагыз ул тәмәкене,”- диде. Әлбәттә инде, берәр ярамаган эш эшләсәң, яки тәртип бозсаң “Сез бит пионерлар, я булмаса комсомоллар,”- дип ачуланалар иде. Әдия апа комсомол эшен дә бик тырышып алып бара иде. Күпме чыгышлар ясадык, күпме эшләр башкарылды...

Хәзерге олырак яшьтәге кешеләр барысы да диярлек комсомолдан чыккан. Бәлки яшь чаклар булгангадыр, ул вакытлар бик күңелле, матур булып искә төшә. Барлык эшләгән эшләр пионер, комсомол байрагы астында үтте. Көл, кош-корт тизәге, макулатура, тимер-томыр җыябызмы, өлкәннәргә булышабызмы – нинди генә эш эшләсәк тә пионер, комсомол исеме белән башкарылды, тырыша-тырмаша план тутыра идек. Ничек кенә булмасын, яшьләр белән эш һәрвакыт алып барыла иде.

90нчы еллар барысын да юкка чыгарды. Башта патриотик эш алып барулар тыелды. Тәрбия эшен юкка чыгардылар. Ә аны башка нәрсә белән алмаштыра алмадылар. Татарстан варислары дигән оешма да барлыкка килде. Ләкин, югарыдан хуплаучы бик булмаганга күрәдер инде, ул да озакка бармады. Шулай итеп, яшьләр беркемгә дә кирәкмәс булып калды. Башланды наркомания, разврат, үтерешү-көчләүләр... Хәзер нәрсә югалтканнарын аңлый башладылар, ахрысы. Җимерү генә җиңел бит ул, ә менә яңадан төзеп кара син аны! Мәктәптәге, балалар бакчасындагы хәлләрне карагыз сез. Укытучыларга, тәрбиячеләргә бик авыр эшләве. Балалар белән эшләргә була, ә менә аларның ата-аналары белән аеруча авыр. Үзләренең җаваплылыгын онытып, русча итеп әйтсәк, праваларын гына качать итәләр. Алар бит 90нчы елгы кешеләр...

Ә бүген комсомолга 100 ел. Менә шуңа күрә пионер да, комсомол да аеруча якын булып искә төшә.

Кадерле комсомоллар! Сезне комсомолның 100 еллыгы белән тәбрик итәм, сәламәтлек, озын, тыныч гомер, бәхет-шатлык телим.

НЕ РАССТАНУСЬ С КОМСОМОЛОМ, БУДУ ВЕЧНО МОЛОДЫМ!!!

Махмутова Әнисә.







